# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

## КАРАР

07 08 2026 ел Яр Чаллы ш. №2701

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру турында» Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 29 августындагы 3594 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законга һәм «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 34 статьясына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 1 һәм 2 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 2026 елның 26 июнендәге 206-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру турында» Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 29 августындагы 3594 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. II бүлекнең 2.9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршруты, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршруты әлеге Федераль законның 26 статьясы 1 өлеше 1-11 пунктларында каралган белешмәләр даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның тиешле маршрутлары реестрларына кертелгән көннән, әлеге Федераль законның 26 статьясы 1 өлеше 3-11 пунктларында каралган әлеге маршрутлар турында белешмәләр шушы реестрларда үзгәргән көннән билгеләнгән яисә үзгәртелгән дип санала.

Әгәр кимрәк сроклар даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршруты, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык бирелгән юридик зат, шәхси эшкуар яисә гади ширкәт шартнамәсенең вәкаләтле катнашучысы белән килештерелмәгән булса,

мондый таныклыкның гамәлдә булу срогы дәвамында аны билгеләгән Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы яисә җирле үзидарәнең вәкаләтле органы инициативасы белән тиешле маршрутны үзгәртү йә юкка чыгару турында карар мондый таныклыкның гамәлдә булу срогы тәмамланган көнгә кадәр йөз сиксән көннән дә соңга калмыйча кабул ителә һәм мондый таныклыкның гамәлдә булу срогы тәмамланганнан соң үз көченә керә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), рәсми сайтта (tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең төзелеш, архитектура һәм халык яшәешен тәэмин итү мәсьәләләре буенча урынбасары Д.Ф. Вәлиуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе Л.Н. Маняпов